

Ләмберә халкынын унганлыгы турында газетабыз битләрендә сойләп киләбез. Матур-матур йортлары, яшәv-челәр ярдәме белән тозекләндерелгән юллары, ял урыннары, елга-кvл буйлары... Бvген сvзебез юллар турында.
- Хәрәкәт бер-беребезгә капма-каршы булырга тиеш, - ди Рашид Ярбек улы Янгибаев (фотода vткән ел ремонтлаган Гражданнар урамы юлында), - кече хужалыклар кирәкле жиһазлар сатып ала, ә жирле бюджет юл полотносын тозекләv буенча алар белән гарантияле килешv този. Шулай булган юлларыбызны сакларбыз да.      Бvген кvпторле технологияләр заманы. Зур акчалар әрәм итмичә генә юлларны менә дигәнчә тозекләндереп була, икән. Полимер типтагы салкын асфальт белән юлнын ябынчасын-покрытиясен тозекләндереп була. Шундый салкын асфальт бәясе дvрт йоз сум булган илле килограммлы капчыкларда сатыла. Илле миллиметр калынлыктагы бер квадрат метр юлны ремонтлау очен бер капчык салкын асфальт житеп тора. Жиһазлардан - бензин виброплитасы, швонарезчик һәм тояv инвентаре кирәк.
Бу коннәрдә Ләмберә урамнарынын берсендә юл чокырларын югарыда әйтелгән технология буенча ремонт эшләре алып барылды. Юлчыларнын берсе: «Зачем вы впустую тратите время и средства, пройдут несколько КАМАЗов по щебенке, которой вы засыпаете ямы, и выбьют ее, колдобины обнажатся вновь», - дип машинасында vтеп китте.
Кооператив председателе Рашид Ярбек улы Янгибаевны бу сvзләр яна эшлекле тәгъдим белән «Призыв» газетасы редакциясенә килергә мәжбур иткән: «Районыбызда юлларны ремонтлау буенча кече хезмәт булдырырга кирәк. Кайчандыр Ләмберәдә ДРСУ эшләде, каты ябынчалы юлларыбызда тәртип кvбрәк булды. Якташларым яхшы хәтерлидер, бу предприятия хезмәткәрләре юлдагы кvлдәвекләрне жибәртеп, торбаларны чистартып, юлларга олешчә ремон биреп тордылар. Бу оешма кvптән таркалды. Безнен кооператив олешчә бу вазыйфаларны vзенә йокләргә әзер.
ДРСУга алмаш буларак, юлларны ремонтлау буенча кече предприятиесе асфальт юлларнын халыкка хезмәт итvен унлап елларга арттырыр иде. Мәсәлән, халык телендә притчага әйләнеп килгән Крестьяннар урамын ремонлауны алыйк. Бу урам юлына капиталь ремон бирv очен егерме миллион сумнан артык акча кирәк. Шул ук конне авылыбызнын башка урамнары да котә. Букадәр зур сумманы каян аласын инде? Жирле бюджетта мондый зур акча юк. Шуна юлны очсызга ремонтлау технологияләре – актуаль мәсьәлә. Бу тенологияне башкаручысы булган очракта гына эшкә жинеп була, чокырлы ремонт башкаручы оешма булса гына. Зур юл тозәтv компанияләре ремонт очен зур акчалар сорый. Безнен очракта оч-дvрт кешелек оешма юлларны озак еллар тәртиптә

тота алыр иде дип уйлыйм».
Бvген кайбер кешеләр, vз теләкләре белән, ой тирәләре чокырларын кирпеч ватыклары беләр тутырып килә. Бу берничә елга житvен-житә: кирпеч ватыклары чокырларны тагы да кинәергә бирми. Ә остенә асфальт ваклары жәйсән, шундый ремонт озак елларга чыдар иде. Шундый фикерләр Р.Я.Янгибаевта байтак. Хәтердә, vткән елны Ярбек улы Рашид, уллары Ринат һәм Равиль белән, 204 тонна асфальт валчыгы, йоздән артык тонна щебень, аерым техника эшен тvләп, оч йоз мен сум акчаларын туздырып, Гражданнар урамын ремонтлап ясадылар дип язган идек.
«Бvген юл бик яхшы сыйфатта, чонки асфальт крошкасын кvптонналы каток белән тигезләп чыктык. Булган юлны саклый да белергә кирәк бит. Бу технология киләчәктә дә бюджетнын зур суммаларын экономияләр дип уйлыйм. Мона илебез житәкчесе дә чакыра»,- дип сvзен йомгаклый Рашид Ярбек улы Янгибаев.
P.S: Райvзәк чокырларын ремонтлаган юл эшләре хезмәткәрләре колагына: щебеньга ( для вязкости) «майлы» балчык кушарга кирәк - бер сезонга точно житәр.
Шундый кинәшнен башкаларга да кирәге чыгуы бар.

**Н.Хәлил әзерләде**